**Татарстан Республикасы Апас муниципаль район Советы**

**Карары**

2018 ел, 24 август № 176

**Татарстан Республикасы Апас муниципаль районында бюджет төзелеше һәм бюджет процессы турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында**

"Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, РФ Бюджет кодексы, Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Советы карар итте:

1. "Татарстан Республикасы Апас муниципаль районында бюджет төзелеше һәм бюджет процессы турында” 2013 ел, 8 ноябрь 166 номерлы Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Советы карары белән расланган Татарстан Республикасы Апас муниципаль районында бюджет төзелеше һәм бюджет процессы турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

8 статьяның 3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“3. Район бюджеты акчаларын баш бүлүче судта муниципаль берәмлек исеменнән муниципаль берәмлеккә карата тубәндәге дәгъвалар буенча җавап бирүче вәкиле буларак чыгыш ясый:

1)җирле үзидарә органнарының яисә әлеге органнарның ведомствога караган вазыйфаи затларының законсыз гамәлләре (гамәл кылмау) нәтиҗәсендә физик затка яисә юридик затка, шул исәптән законга яки башка хокукый актка туры килми торган җирле үзидарә органнары актларын чыгару нәтиҗәсендә китерелгән зыянны каплау турында дәгъвалар;

2) акчалата йөкләмәләрен үтәү өчен казна учреждениесе булган бюджет акчаларын алучыга җиткерелгән бюджет йөкләмәләре лимитлары җитмәгән очракта бирелгән дәгъвалар;

3)муниципаль берәмлек бюджеты акчаларын баш бүлүченең вәкаләтләрен Россия Федерациясе Бюджет законнары нигезендә гамәлгә ашыручы орган федераль закон нигезендә муниципаль берәмлек мәнфәгатьләрен яклаган очракларда муниципаль берәмлеккә карата башка дәгъвалар.

2.Әлеге карарны Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы рәсми сайтыда һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырырга.

3.Әлеге карар рәсми рәвештә бастырганнан соң көченә керә.

**Апас муниципаль район**
**Советы рәисе,**
**Апас муниципаль район**
**Башлыгы** **Р.Н. Заһидуллин**